DOI: 10.26907/2311-2042-2020-14-1-147-156

# “NO, MY SOUL DOESN’T AGREE! LIMITED FAITH IS NARROW FOR ME...” (ON THE 140TH ANNIVERSARY OF SAGIT RAMIEV’S BIRTH)

**Chulpan Zaripova-Cetin,**
Kafkas University,
36000, Kars, Turkey,
chulpancetin@gmail.com.



In the poetry of the early 20th century Sagit Lutfullovich Ramiev (1880–1926) is known as a writer, romantic poet, rebel, publicist, journalist, translator, and public figure. His poetry sounded as an anthem of an active human person. Putting Tatar poetry on the rails of rebellious romanticism, he opened a new page in the history of Tatar literature. In anticipation of “the dawn”, S. Ramiev, who shared the aspirations of his people, in his works, he expressed the sorrows and pain of his contemporaries. He declared a rebellion against reality and an unfair way of life. His work reveals the secret movements of his soul. S. Ramiev showed new possibilities of Tatar poetry, creating free poems based on conversational intonation. The writer became famous not only as a poet, but also as a talented playwright and novelist.

XX йөз башы татар шигъриятендә үтә нечкә күңеле белән дөнья кысаларына сыймаган давыллы романтик һәм гыйсьянчы шагыйрь, язучы, драматург, публицист, журналист, тәрҗемәче, әдәбият һәм сәнгать белгече, «таң»чы Сәгыйть Рәмиев (1880–1926) аерым урын биләп тора. Әдәбиятны алга этәрүче, кеше рухының бөеклегенә һәм матурлыгына мәдхия укыган яңа сыйфатлы актив романтизмның барлыкка килүе татар әдәбиятында Сәгыйть Рәмиевнең иҗаты белән бәйле. Татар халкының «таң вакыты»н жырлаган, яшәгән чорның кыйгы һәм әрнү тулы чынбарлыгына каршы гыйсьян белдергән, халыкның изелүенә һәм хакларының кулыннан алынуына каршы ләгънәт укыган романтик герой татар шигыренә С. Рәмиевнең шигырьләре белән керде. Бөтен иҗатын кешенең эчке дөньясын ачуга багышлаган

В поэзии начала XX в. Сагит Лутфуллович Рамиев (1880–1926) известен как писатель, поэт-романтик, бунтарь, публицист, журналист, переводчик, общественный деятель. Его поэзия прозвучала гимном активной человеческой личности. Поставив татарскую поэзию на рельсы бунтарского романтизма, он открыл новую страницу в истории татарской литературы. С. Рамиев, живший чаяниями народа, в ожидании «рассвета» выразил в своих произведениях горести и боль современников, объявил бунт против действительности, несправедливого уклада в обществе. В его творчестве раскрываются сокровенные движения души. С. Рамиев раскрыл новые возможности татарской поэзии, создавая свободные стихотворения, основанные на разговорной интонации. Писатель прославился не только как поэт, но и как талантливый драматург и прозаик.

С. Рәмиев татар шигыренең яңа мөмкинлекләрен ачты, сөйләм теленә корылган ирекле шигырь иҗат итте. Шагыйрьнең шигырьләре генә түгел, пьесалары, повесть һәм хикәяләре дә татар драматургиясе һәм прозасынын алга китүендә әһәмиятле роль уйнады.

Sagit Ramiev was born on February 12 (24), 1880, in the village of Akman (Ibrai) in the Orenburg province. By his origin, he came from the noble family of the Ramievs, who gave Tatar literature, if we take into account Derdemend, two great poets. His father Lutfulla was educated, he traded in wood. He was also hired by wealthy wood producers to fuse wood [Sadretdinov, 1980, p. 5]. At the end of his days, he was an unremarkable mullah in his village [Ayupova-Ramieva, 2005, p. 114]. As S. Ramiev's childhood passed in different places, he was brought up on the written and oral folklore of the Tatars, Bashkirs and other kindred peoples, living in the steppe; he learnt such melodic songs as "Ashkazar" and "Alluki". The connoisseur of Tatar literature Sh. Sadretdinov writes, "S. Ramiev fascinated every-one with his beautiful and sincere singing". According to scientist M. Gali, the famous poem by G. Tukay "Milli Monnar" ("Folk Motifs") was inspired by the song "Alluki" performed by "the most beloved singer", S. Ramiev [Ramiev, 1980, p. 255]. S. Ramiev went to the elementary school in the town of Ilek on the banks of the Ural River. In 1890-1902, he studied at the "Khusainia" Madrasah in Orenburg. In those years, he studied at the Russian school with three classes of instruction. While S. Ramiev was still in the madrasah, Gayaz Iskhaki came to teach there and began to change various spheres of students' lives. He taught students new disciplines, read new books, held literary evenings, tried to acquaint students with the Russian theater, and thereby won universal love. Sagit Ramiev also joined the new trend, and on the advice of the new mentor, he got interested in Russian literature, went to Russian theaters, and began to write poems. After graduating from the madrasah with honors, he worked there as Farsi, geometry and algebra teacher. However, at the end of 1905, disagreeing with the foundations of the madrasah, and rejecting the proposed status of the imam, he left the madrasah together with his students.

In early 1906, Sagit Ramiev arrived in Kazan and participated in the organization of the newspaper "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn"). The actual supervisor of the newspaper "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn") was G. Iskhaki, the man who was its spiritual leader. However, he could not take on the responsibilities of an editor and the official editor and publisher of the first newspaper was G. Petrakov, later F. Tuktarov and S. Ramiev. In his revolutionary-democratic articles, S. Ramiev showed the fate of the people closely linked with the history of the country, wrote the hottest political articles under his own name and under various pseudonyms, published his poems. But later, the newspaper "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn"), led by G. Iskhaki, and its responsible editor S. Ramiev faced persecution, as a result, on 16 November, the newspaper "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn") was closed. To continue the "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn"), the newspapers "Tan Mazhmugasy" ("Collection of the Dawn") and "Tavysh" ("Voice") were released under G. Iskhaki's ideological leadership. However, their fate was short. From the beginning of June, 1907, S. Ramiev, deprived of the rostrum, newspapers and a job, began to work in the newspaper "Bayanelkhak" ("Clarifying the Truth"). Researcher M. Gaynutdinov made an important conclusion, based on numerous facts: "As early as in 1908, from the beginning of February, "Bayanelkhak" became the newspaper of "the Dawn" publishers, G. Iskhaki joined this newspaper earlier than S. Ramiev. His works, written during his exile to Arkhangelsk, were published by his friends, who remained free in "Bayanelkhak": Kh. Abuzyarov and S. Ramiev" [Gaynutdinov, 1997, p. 77]. In the summer of 1910, S. Ramiev was invited to Astrakhan to work in the newspaper "Idel" ("The Volga"). He soon became the actual editor of this newspaper, raised relevant topics in the language accessible to people, wrote articles related to literature, art and versification, made translations [Sadretdinov, 1973, pp. 41-43]. According to S. Ramiev's friend, a well-known journalist Kasim Girfanov, the

poet's arrival in Astrakhan took place at a time when, after the revolutions of 1905-1906, culture and education revived in the city. The Labour Party, organized by local Tatars, came to the forefront of public work, when in 1909, the Azerbaijan revolutionary, writer, Dr. Nariman Narimanov was exiled to this city [Girfanov, 1965, pp. 152-153]. S. Ramiev and N. Narimanov worked in close cotact, jointly participated in the cultural life of the city, organized literary and musical parties and performances. The appearance of the Tatar Folk Theater in Astrakhan was associated with the names of N. Narimanov and S. Ramiev. These two great personalities jointly worked to help schools and poor children, and took an active part in the work of People's University. To raise money for TB patients a "Celebration of the White Flower" was held during the flowering of daisies. In April 1911, at the invitation of S. Ramiev, G. Tukay came to Astrakhan. At first, he lived in the hotel, and later, at his own request, moved to Sagit Ramiev's place. S. Ramiev acquainted Tukay with N. Narimanov, and asked him to examine Tukay as a doctor. Although he believed that Tukay's disease was incurable, N. Narimanov, told him to be treated with kumis, and provided the poet with financial support. In order to be treated with kumis, Tukay settled on the edge of the city in the village of Kalmyk Bazar, in the house of teacher Shakhit Gayfi. S. Ramiev visited his friend almost daily bringing him newspapers and magazines. Having slightly improved his health, Tukay was satisfied with his stay in Astrakhan. As a sign of respect, S. Ramievg gave him a magnificent farewell [Girfanov, 1965, pp. 152-154]. In Astrakhan, S. Ramiev closely interacted with the artist and director Zayni Sultan and playwright Gafur Kulakhmetov.

According to researcher Sh. Sadretdinov, who thoroughly studied S. Ramiev's work, "in early 1912, the Ministry of the Interior sent an order to the Kazan Censorship Committee to check the newspaper "Tan Yoldyzy" ("The Star of the Dawn") again. According to the results of the inspection, more than twenty newspaper issues were arrested, included in the list of banned literature, the Kazan court and the gendarmerie authorities began to search for S. Ramiev [Sadretdinov, 1994].

When on October 22, 1913, in Petersburg, the Tatar newspaper "Il" ("The Country") edited by G. Iskhaki finally was released, S. Ramiev was also engaged in its work along with such prominent public figures as Yu. Akchura, M. Bigiev, A.-Z. Validi, Sh. Mukhamedyarov, F. Tuktarov, etc. In early 1914, the newspaper "Idel" ("The Volga"), where S. Ramiev worked, was closed and the poet was exiled from Astrakhan and had to move to Ufa together with his wife Banu Ayupova. Here, he translated the journal "The Agricultural Leaf" into Tatar and published it. Along with famous writers Mazit Gafuri and Galimzan Ibragimov, he contributed to the literary and cultural movement of Ufa. However, S. Ramiev's life in Ufa was not a bed of roses. In early January 1916, the gendarmerie tried to make S. Ramiev a secret agent. From this time on the name of S. Ramiev was associated with the nickname "an agent provocateur". After the October Revolution, in January, 1918, in Ufa, the National Assembly was held where S. Ramiev admitted that he had no intention to betray his people, but this gossip, without any grounds, persisted in the 1920s [Sadretdinov, p. 170]. Sagit Ramiev faced a lot of injustice, and being a vulnerable person, he took it close to heart. Persecution, consecutive loss of two children, having to move from city to city, hunger and spiritual depression because of the situation with the gendarmerie in 1914-1916, mistrust, created by the new government – all these events tormented the poet with a subtle soul. The poet, who had previously expressed rebellion and protest against God, began to seek His consolation. Sagit Ramiev was a poet who believed in the existence and oneness of Allah. His poem "Allah" proves that. His poems "They", "Prayer", "Consolation" have verses from the Quran as an epigraph or epilogue. At the initial stage of his work, he expressed disagreement with Allah, he was lost due to the trials of life. S. Ramiev was newly drawn to Allah. His poems "A Prayer", "Consolation", "Tired" express anguished feelings, resentment, anger, and appeal for protection to the Quran. Not only the poet but also his creative heritage had a tragic fate. Most of his manuscripts, photographs disappeared and are still not found. Several volumes of selected works were sent to mass media and also disappeared. On March 23, 1917, the national-patriotic newspaper "Il" was first issued in Moscow. S. Ramiev actively contributed to this newspaper, in issue 23 with the words "Dedicated to Gayaz Efendi and his friends", he published the poem "They" written in the same year. In 1918, on the fifth anniversary of G. Tukay's death, he published an article "Maktub" ("Letter") in Astrakhan newspaper "The Saray" (1918, 3(17) April). In this poem S. Ramiev, referring to the soul of his close friend,

described the political changes that had occurred in the country. It was with pain that he wrote that freedom was merely declared, in fact, horrific events took place in the country. According to the memories of the poet's wife, in the autumn of 1918, with the change of the government in Ufa, S. Ramiev's friends came and asked him to join them and go to Siberia. However, burdened with a family, accused of being an agent provocateur and barely justified, the poet could not accept this plan [Ayupova-Ramieva, 2005, p. 114].

As early as in 1918, S. Ramiev, with a sensitivity inherent only in poets, guessed what the changes in the country would lead to and openly wrote about it. The poet, working in the revolutionary committees, saw a lot, during the time of famine he helped to collect dead bodies, his still-not-found work "The Devil Also Startled"is devoted to these events. During the Soviet rule, the poet did not write a single poem supporting the events in the country. His contemporary writer, journalist and public figure D. Yultyi was right, even being involved in various Soviet affairs, "the inner spirit of Sagit Ramiev could not get used to the new time. This time could not give impetus to his creative talent "[Yultyi, 1926]. In the Soviet period, S. Ramiev either went over to the Reds, or remained somewhere in the middle. In the 1923, in the newspaper "Bashkortstan", the article "To Sagit Aga" by Gasim Kasimov was published on January 11, it accused S. Ramiev of not being able to become a poet of new literature, based on political relations in the era of worker-peasant dictatorship. The poet answered him with his poem "My Word and I". Unable to find peace of mind and inspiration in modern times, S. Ramiev died in March 1926 from a lung disease.

S. Ramiev was a poet, unique, unparalleled in Tatar literature, a romantic in worldview. In his poetry there is a depth of thought, a philosophical view of the world and everything that exists in it. His contemporaries considered S. Ramiev to be a poet capable of thinking, noted the depth of thought in his poems, admired the beauty of descriptive means, claimed that among the poems published in the Tatar language, his poems were unsurpassed in strength.

Tatar literature of the early 20th century, while remaining true to Oriental roots, at the same time, was open to innovations of European literature. This phenomenon was characteristic of poetry, prose, and drama. As can be seen from the works of famous Tatar literary critics G. Khalit, R. Ganiev, Kh. Minnegulov, the era of renovation occurred in Tatar literature of the early 20th century and philosophical, social, aesthetic and ethical ideas of the East with a hitherto unseen force. Therefore, without any doubt, many Eastern poets and thinkers of the Middle Ages had an impact on S. Ramiev. Even while in the madrasah, the poet studied ancient Eastern poetry, especially Persian poetry with interest. He read the works of such classical poets in the original, as Firdausi, Sagdi. S. Ramiev's rebellious spiritual and creative aspirations were especially in tune with revolutionary and atheistic ideas found in the works of Khayyam, Khafiz, Nasimi, and other poets. To understand S. Ramiev's rebellion we should turn to pantheism, which emerged in Sufism in the Middle Ages and encouraged independent thinking, attracting passionate people, helping them to stay in Islam and at the same time to get out of it to reality. In the pantheism of the Middle Ages, God and the universe were treated as a single entity. Pantheistic Sufism arose in the East in the works of Azerbaijan poet Imameddin Nasimi. It awoke a deep sense of respect for the individual, glorifying the greatness of man. The fact that in his poem "Allah" S. Ramiev wrote, "I am He, He is I!" recalls Nasimi's idea "Allah is man". The thoughts and actions of the poet reached greatness, his soul recognized Allah and accepted Him as a single entity with His own "I". Both Nasimi, and Ramiev praised, not everyone, but a free, majestic personality. Pantheists, inspiring love and respect for the personality, explained love as a divine force animating the whole world. S. Ramiev also praised great, pure love. He believed that divine creatures, living on Earth, had absorbed the beauty of the Universe, he admired them, had high hopes concerning them, believed that the mission of women is to preserve and renovate the nation.

His poems, written in 1906-1910, the poem "Sunrise" in particular, dedicated to the awakening of the Tatar people's consciousness have not lost their relevance today. The poem "I" says that the soul was created by Allah, it does not fit into the framework of written revolt addressed to the Earth and the Sky, which have no equals in the world in terms of the self and independence. His poems "He", "You", "Jamila", glorifying the beauty of women, describing women as divine creatures – all of them are the gems of world poetry. S. Ramiev's poems are easily read in the context of Russian literature. He often refers to Russian poetry, in particular the poems by M. Lermontov, K. Balmont, he draws inspiration from them. In the

poems of S. Ramiev along with rebellion coming from Oriental literature, there is a demonic element, coming from Russian literature, from Lermontov and Balmont (“I”, “Let Them Laugh”, “To the World”, “Mazit’s Word”). At the same time, S. Ramiev’s poems, filled with deep philosophical meaning, are consistent with the philosophy of existentialism, which emerged in the late 19th – early 20th century in the West. Such motifs as the inevitability of fate, the impermanence of anything in this world, the constant change of all, the senselessness of human existence are found in S. Ramiev’s works. The sadness of separation from the world, solitude, death, and such philosophical, existential motifs are more typical of such poems as “I’m Dying” and “ I wasn’t Fun”. Examining S. Ramiev’s work **a**gainst the background of classical Eastern and Western philosophical poetry of the early 20th century, we see his creative independence and the place that he occupies in the development of national and world literature.

G. Ibragimov was able to consider the most important aspects of Sagit Ramiev’s creative work: in his dreams, the poet was flying away from the petty, simple life to the depths of the Universe, but in reality, he was forced to live surrounded by hated and low life. The poet thought it was his tragedy [Ibragimov 1978, p. 96]. As it is known, the separation from human community, existence in splendid isolation is the desire of poets, they need to save themselves as personalities, enjoy limitless, absolute freedom and this is typical of all romantic poetry. Later, as literary critics Kh. Gosman and G. Khalit write, “both Sagit Ramiev, and Derdemend believed that ‘personality and inspiration need to be aloof and above the people’” [Khalit, 1979, p. 156]. Among the features that allowed us to place S. Ramiev next to world poets-classics – Byron, Goethe, Lermontov, Nietzsche, Gibran, Balmont is his hopelessness and individualism. His most beautiful and powerful poems were created during the period of dark reaction within hopelessness. G. Ibragimov was right in determining S. Ramiev as “a true poet, not guided by cold reason and dry logic” [Ibragimov 1978, p. 84]. All his life S. Ramiev was a sensitive person often suffering from depression, not knowing what to do, experiencing the inability to protect himself– all these contributed to the emergence of dramatic changes of mood reflected in his poetry and drama. However, even in the poems written during the period of dark reaction (1909-1911) and expressing deep resentment in his poems “Deceived”, “I’m Dying”, “Let Them Laugh”, “To the World”, “My Night”, Sagit Ramiev hoped for a bright future of the Tatars and the whole of humanity, believed that the dark night would be followed by the dawn. His lyrical character, despite the dominance of evil in the world, strived for perfection and harmony.

Along with poems, S. Ramiev wrote short stories, novels and dramatic works on current topics of that time. His comedy “Raised Madrasah”, completed in 1907 and published as a separate book in 1908 was staged by the Sayyar troupe. It is based on the events that took place in the “Husainia” Madrasah, one of the leading madrashs of that time. However, it did not meet the expectations of the advanced Tatar youth of the early 20th century. In the play “Live, Zubaida! – I Live!”, written in the same 1907, S. Ramiev, along with the problems of education and upbringing that came to the fore at the beginning of the twentieth century, showed the independence of women and the moral searches of the advanced Tatar intelligentsia. His characters were educated, free-thinking, looking for ways to serve their people, able to fight for their ideals and personal love.

S. Ramiev along with G. Kamal, G. Iskhaki, F. Amirkhan and G. Kulakhmetov took an active part in the creation of the Tatar theater. On December 2, 1906, the first official performance in the history of the Tatar theater began with the fiery speech of Sagit Ramiev and the poem “Theater”, dedicated to Tatar artists who first appeared on the stage. S. Ramiev also wrote many articles related to the history of the theater and criticism.

Those were hard times, full of sharp clashes, poets and poetry were forced to be smeared in political colors. The tragic fates of Gabdulla Tukay, Derdemend, Gayaz Iskhaki, Fatikh Amirkhan, Galimzan Ibragimov and many other poets and writers testify to this fact. Therefore, it is not surprising that in Sagit Ramiev’s poems we find heartbreaking suffering, disagreement with the world, and despondency.

**References**

Aiupova-Ramieva, G. (2005). *Istaleklar* [Memories]. “Uilasam ui, syzlyi kүңlem, syzlyi җan...”: Sәgyit' Rәmievneң tormysh iuly hәm iҗatyna karata iaңa mәg"lүmatlar. Tөzүche-avtor Chulpan Zaripova-Cetin. Kazan, Ianalif. Pp. 106-118. (In Tatar)

Gaynutdinov, M. (1997). *Gabdulla Tukay ham Sagyit Ramiev* [Gabdulla Tukay and Sagit Ramiev]. Tukai hәm XX gasyr mәdәniyate. Shagyir'neң 110 ellygyna bagyshlangan halykara konferentsiia materiallary. Pp. 72-80. Kazan. (In Tatar)

Girfanov, K. (1965). *Sagit Ramiev turynda kayber istaleklar* [Some Memories of Sagit Ramiev]. Kazan Utlary. No. 6. Pp. 148-156. (In Tatar)

Ibragimov, G. (1978). *Tatar shagyirlare.* [Tatar Poets. G. Ibragimov. Works: in 8 vol.. Vol. 5, pp.74-156. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

Iulty D. (1926). *Sagit Ramiev ulde* [Sagit Ramiev Died]. Eshche. No. 53 (March). (In Tatar)

Khalit, G. (1979). *Iana gasyr poeziiase* [New Century Poetry]. 168 p. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

Ramiev, S. (1980). *Tan vakyty* [The Time of Dawn. Poems, Short Stories, Plays, Journalism]. 272 p. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

Sadretdinov, Sh. *Arkhiv materiallary ni soyli?* [What do Archival Materials Say? A Manuscript]. Sadretdinov arhivy. TӘҺSI miraskhanәse, 170 f. (In Tatar)

Sadretdinov, Sh. (1980). *Sagit Ramiev* (1880-1926). [Ramiev, Sagit. Time of Dawn]. Shigyr'lәr, hikәyalәr, sәhnә әsәrlәre, publitsistika. Pp. 4-16. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

Sadretdinov, Sh. (1973). *Sagit Ramiev izhaty* [Sagit Ramiev's Work]. 162 p. Kazan, Tatar kit. nashr. (In Tatar)

Sadretdinov, Sh. (1994). *Sagit Ramiev kham patsha zhandarmeriyase* [Sagit Ramiev and the Royal Gendarmerie]. Argamak. No. 6. Pp. 92–101. (In Tatar)

# «ЮК, КАНӘГАТЬ ИТМИ КУҢЕЛЕМ! ТАР МИҢА ЧИКЛЕ ИМАН...» (СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВНЕҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ УҢАЕННАН)

**Чулпан Зарипова-Четин,**
Кавказ университеты,
36000, Карс, Төркия,
chulpancetin@gmail.com.

Сәгыйть Рәмиев 1880 елның 12 (24) февралендә Оренбург губернасы Акман (Ибрай) авылында туа. Чыгышы белән, Дәрдемәндне дә истә тотсак, татар әдәбиятына ике бөек шагыйрь биргән затлы Рәмиевләр нәселеннән була. Әтисе Лотфулла укыган кешеләрдән саналган, агач белән сату иткән. Урман эшләтүче байларга ялланып сал да агызган [Садретдинов 1980, б. 5]. Ә картлык көнендә яшәгән авылында указсыз мулла булып торган [Әюпова-Рәмиева, 2005, б. 114]. С. Рәмиевнең балачагы төрле җирләрдә уткәнгә күрә, ул татар, башкорт һәм далада яшәгән башка тугандаш халыкларның язма һәм авыз иҗатын, «Ашказар», «Әллүки» кебек җыр-көйләрен күңеленә сеңдереп үсә. Татар әдәбияты белгече Ш. Садретдинов язуынча, «С. Рәмиев, матур һәм моңлы тавышы белән җырлап, кешеләрне сокландыра торган булган». М. Гали күрсәтүенчә, Г. Тукайның атаклы «Милли моңнар» шигыре «иң яраткан җырчысы» С. Рәмиевнең «Әллүки»не җырлавын тыңлаудан тәэсирләнеп язылган [Рәмиев, 1980, б. 255]. С. Рәмиев башлангыч мәктәпне Урал суы буендагы Иләк шәһәрендә тәмамлый. 1890–1902 елларда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Шул ук елларда өч сыйныфлы рус мәктәбендә дә укый. С. Рәмиев мәдрәсәне тәмамлар алдыннан, бирегә мөгаллим булып Гаяз Исхакый килә һәм шәкертләр тормышының төрле өлкәләрен үзгәртергә тотына. Гаяз Исхакый шәкертләргә яңа фәннәр, яңа китаплар укытып, әдәбият ахшамнары үткәреп, рус театры белән дуслаштырырга омтылып, барысының да мәхәббәтен яулый. Сәгыйть Рәмиев тә бу яңа хәрәкәткә кушылып китә һәм, яңа мөгаллимнең киңәшен тотып, рус әдәбияты белән кызыксына, рус театрларына йөри, шигырьләр яза башлый. Мәдрәсәне бүләкләү белән тәмамлап чыккач, ул биредә фарсы теле, геометрия һәм алгебра фәннәреннән мөгаллим итеп калдырыла. Ләкин мәдрәсә тәртипләре белән килешмичә, тәкъдим ителгән имамлыкны да кабул итмичә, 1905 ел азакларында шәкертләр белән бергә, мәдрәсәне ташлап чыга.

1906 ел башында Сәгыйть Рәмиев Казанга килә һәм «Таң йолдызы» газетасын чыгару әзерлегендә катнаша. «Таң йолдызы» газетасының фактик җитәкчесе, аңа рух биреп торучы кеше Г. Исхакый була. Ләкин мөхәррирлек вазифаларын үз өстенә алырга мөмкинлеге булмау сәбәпле, газетаның рәсми мөхәррире һәм нәшире башта М. Путиляков, аннары Ф. Туктаров һәм С. Рәмиев исәпләнәләр. С. Рәмиев революцион-демократик характердагы мәкаләләрендә халык язмышын ил язмышы белән бербөтен итеп күрсәтә, үз имзасы һәм төрле псевдонимнар белән кайнар сәяси мәкаләләр яза,

шигырьләрен бастыра. Әмма озак та үтми, Г. Исхакый җитәкләгән «Таң йолдызы» газетасын һәм аның җаваплы редакторы С. Рәмиевне эзәрлекли башлыйлар һәм 16 ноябрьдә «Таң йолдызы» газетасы ябыла. «Таң йолдызы»ның дәвамы буларак, Г. Исхакый идея җитәкчелеге астында «Таң мәҗмугасы» һәм «Тавыш» газеталары чыга башлый. Ләкин аларның да гомерләре озын булмый. 1907 елның июнь башыннан С. Рәмиев трибунасыз, матбугатсыз һәм эшсез калгач, «Бәянелхак» газетасына килеп керә. Галим М. Гайнетдинов, шактый материаллар туплаганнан соң, кыюмматле нәтиҗә ясый: «1908 елда ук, февраль башларыннан, «Бәянелхак» «таңчы»лар газетасына әйләнә, ягъни бу газетага С. Рәмиевтән алдарак Г. Исхакый килеп керә. Аның Архангельдә сөргендә язган әсәрләрен тагын шул ук «Бәянелхак»та иректә калган Х. Әбүзәровлар, С. Рәмиевләр чыгарып торалар» [Ганетдинов, 1997].

1910 елның җәй айларында С. Рәмиевне Әстерханга «Идел» газетасына эшкә чакыралар. Ул тиз арада бу газетаның фактик редакторы була, халыкка якын тел белән халыкны кызыксындырган темаларны күтәреп чыга, әдәбият, сәнгать һәм шигырь төзелеше белән бәйле мәкаләләр яза, тәрҗемәләр эшли [Садретдинов, 1973, б. 41-43]. С. Рәмиевнең дусты, танылган журналист Касыйм Гыйрфанов язуынча, шагыйрьнең Әстерханга килүе 1905-1906 революцияләреннән соң шәһәрдә мәдәният һәм мәгарифнең җанланган, җәмгыять эшләре башында җирле татарлардан оешкан эшчеләр партиясе торган, 1909 елда бу шәһәргә сөргенгә җибәрелгән азербайҗан революционеры, язучы, врач Нәриман Нәриманов та килеп кергән бер чорга туры килә [Гыйрфанов, 1965, б. 152–153]. С. Рәмиев белән Н. Нәриманов якыннан аралашып, бергәләп шәһәрнең мәдәни тормышына актив катнашалар, әдәби-музыкаль кичәләр һәм спектакльләр оештыра башлыйлар. Әстерханда татар милли театрның барлыкка килүе дә Н. Нәриманов һәм С. Рәмиев исемнәре белән бәйле иде. Бу ике бөек шәхес шулай ук бергәләп мәктәпләргә һәм фәкыйрь балаларга ярдәм итү эше башлатып җибәрәләр, халык университеты эшендә дә актив булалар. Туберкулёз белән авыручылар өчен ромашкалар чәчәк аткан вакытта «Ак чәчәк бәйрәме» үткәрәләр. 1911 елның апрель аенда Әстерханга С. Рәмиев чакыруы белән Тукай килә. Башта ул кунакханәдә яши, аннары үз теләге белән Сәгыйть Рәмиев янына күчә. С. Рәмиев Тукайны Н. Нариманов белән дә таныштыра, аннан авыру Тукайны врач буларак каравын үтенә. Н. Нәриманов, Тукайның авыруына чара булмаганын белдерсә дә, кымыз белән дәваланырга куша, шагыйрьгә материаль ярдәм дә күрсәтә. Кымыз белән дәвалану өчен, Тукайны шәһәр читендәге Калмык базары дигән авылга укытучы Шәһит Гайфи өенә урнаштыралар. С. Рәмиев һәркөн диярлек дусты янына барып, хәлен белә, газета-журналлар белән тәэмин итеп тора. Тукай Әстерханнан сәламәтләнеп, канәгать булып китә. С. Рәмиев аны хөрмәтләп, олылап озатуны оештыра [Гыйрфанов, 1965, б. 152–154]. Әстерханда С. Рәмиев шулай ук артист һәм режиссёр Зәйни Солтан һәм драматург Гафур Коләхмәтов белән дә якыннан аралашып яши.

С. Рәмиев иҗатын җентекләп өйрәнгән галим Ш. Садретдинов язганча, «1912 ел башларында эчке эшләр министрлыгы Казан цензура комитетына «Таң йолдызы» газетасын яңадан тикшереп чыгарга күрсәтмә җибәрә. Тикшерү нәтиҗәсендә, газетаның егермегә якын санына арест салына, тыелган әдәбият исемлегенә кертелә, Казандагы суд һәм жандармерия органнары С. Рәмиевне эзли башлыйлар [Садретдинов, 1994].

1913 елның 22 октябрендә Петербургта, ниһаять, Г. Исхакыйның үз редакторлыгында йорт-җир файдасын күзәтүче татар газетасы «Ил» чыга башлагач, биредә Й. Акчура, М. Бигиев, Ә.-З. Вәлиди, Ш. Мөхәммәдьяров, Ф. Туктарый һ.б. күренекле җәмәгать эшлеклеләре белән С. Рәмиев тә катнаша. 1914 ел башларында С. Рәмиев эшләгән «Идел» газетасы ябылып, шагыйрь Әстерханнан сөрелә һәм хатыны Бану Әюпова белән Өфегә күчәргә мәҗбүр була. Биредә ул «Сельскохозяйственный листок» журналын татарчага тәрҗемә итеп чыгара башлый. Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов кебек күренекле язучылар белән бергә Өфедә дә әдәби һәм мәдәни хәрәкәткә үз өлешен кертә. Ләкин С. Рәмиевнең Өфедәге тормышы да кара буяуларга буяла. 1916 елның гыйнвар башында С. Рәмиевтән жандармерия яшерен агент ясарга тырыша. Шул көннән алып, С. Рәмиев исеме «провокатор» дигән атама белән пычрана. Октябрь революциясеннән соң, 1918 елның гыйнварында, Өфедә җыелган Милләт мәҗлесе С. Рәмиевнең милләтенә хыянәт нияте булмаган, дип тапса да С. Рәмиев турында төрле имеш-

мимешләр, дәлилсез гаепләүләр үткән гасырның 20 нче елларында да күренгәли [Садретдинов, 170 ф.]. Сәгыйть Рәмиев гаделсезлекләрне күп күрә, нечкә күңелле кеше буларак, аларны авыр кичерә. Эзәрлекләүләр, бер-бер артлы ике баласын югалту, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрергә мәҗбүр булу, ачлык, 1914–1916 елларда жандармерия белән булган вакыйгалардан барлыкка килгән рухи төшенкелек, яңа корылган дәүләт тарафыннан ышанычсызлык - бөтен бу вакыйгалар нечкә хисле шагыйрьнең рухын рәнҗетә. Моңарчы Аллага каршы бунт, протест белдергән шагыйрь күңеле инде әрни-әрни Аллага сыенып, аннан юаныч эзли башлый. Сәгыйть Рәмиев – Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә ышанып яшәгән шагыйрь. Бу аның «Алла» исемле шигыреннән дә күренә. «Алар», «Дога», «Тәсәлла» кебек шигырьләрендә эпиграф яисә эпилог буларак Коръәннән алынган аятьләр дә китерелә. Иҗатының башлангыч чорында Аллаһы Тәгаләгә ризасызлык белдерсә дә, тормыш сынаулары каршында югалып калып, С. Рәмиев янә Аллага сыена. Аның «Дога», «Тәсәлла», «Талдым» кебек шигырьләрендә газаплы кичерешләр, үпкә, ачыну һәм яклау эзләп, Коръәнгә мөрәҗәгать итү күренә. Шагыйрь үзе генә түгел, аның иҗади мирасы да фаҗигале язмышка дучар була. Кульязмаларының, фоторәсемнәренең күбесе юкка чыга, аларның әлегәчә табылганы юк. Берничә томлык сайланма әсәрләре нәшриятка басылырга бирелгән җирдән эзсез югала.

1917 елның 23 мартында Мәскәүдә милли-патриотик рухтагы «Ил» газетасы чыга башлый. С. Рәмиев бу газетада актив языша, 23 санында «Гаяз әфәндегә һәм аның максатташ иптәшләренә багышлана» дигән сүзләр белән шул ук елда язган «Алар» дигән шигырен дә бастырып чыгара. 1918 елда Г. Тукайның үлүенә биш ел тулу уңае белән Әстерхандагы «Сарай» газетасында (1918, 3(17) апрель) «Мәктүб» дигән мәкалә бастыра. Биредә С. Рәмиев якын дустының рухына мөрәҗәгать итеп, илдә барган сәяси үзгәрешләр белән уртаклаша, хөрриятнең бары тик сүздә генә хөррият булуын, чынлыкта исә илдә коточкыч вакыйгалар баруы турында ачынып яза. Шагыйрьнең тормыш иптәше истәлекләренә караганда, 1918 елның көзендә дәүләт алышынып торганда Өфегә С. Рәмиевнең иптәшләре кайтып, үзләре белән Себергә эвакуациягә чакыралар. Ләкин гаилә белән бәйләнгән, әле яңа провокаторлыкта гаепләнеп, көчкә акланган шагыйрь моны кабул итми [Әюпова-Рәмиева, 2005, б. 114].

Инде 1918 елда ук, С. Рәмиев шагыйрьләргә генә хас үтә сизгерлек белән илдә барган вакыйгаларның кая китерәсен күрә белгән һәм бу хакта ачыктан-ачык язып чыккан. Шагыйрь революцион комитетларда эшләп, төрлесен күрә, ачлык елында үле гәүдәләр җыеп йөри һәм бу вакыйгаларга багышлап көнебезгә кадәр табылмаган «Иблис тә дердерәде» дигән әсәр дә яза. Совет хакимияте заманында шагыйрь илдәге вакыйгаларга дан җырлап, бер генә шигырь дә иҗат итмәгән. Замандашы, язучы, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Д. Юлтый хаклы, төрле совет эшләрендә йөрсә дә, «Сәгыйть Рәмиевнең эчке рухы бу яңа дәвергә үзләшә алмады. Бу дәвер аның шигъри талантына көч бирә алмады» [Юлтый, 1926]. С. Рәмиев Совет чорында бер кызыллар ягына чыгып карый, бер урталыкта чайкала. 1923 елда «Башкортстан» газетасының 11 гыйнварда чыккан санында Гасыйм Касыймовның С. Рәмиевне эшче-крестьян диктатурасы дәверендәге икътисадый мөнәсәбәтләрдән туган яшь әдәбиятның шагыйре була алмауда гаепләгән «Сәгыйть агага» дигән мәкаләсе басылып чыга. Шагыйрь аңа үзенең «Сүзем һәм Үзем» дигән шигыре белән җавап бирә. Яңа чорда җанына тынычлык, иҗатына илһам ала алмаган С. Рәмиев 1926 елның март аенда үпкә авыруыннан тилмереп, вафат була.

С. Рәмиев – уникаль, татар әдәбиятында тиңе булмаган, дөньяны күзаллавы һәм кабул итүе белән романтик шагыйрь. Аның шигъриятендә фикер тирәнлеге, дөньяга, һәр нәрсәгә тирән фәлсәфи караш бар. Замандашлары да С. Рәмиевнең фикер йөртүче шагыйрь булуына, шигырьләрендә мәгънәләрнең тирәнлегенә, тасвирларның матурлыгына сокландылар, татар телендә чыккан шигырьләр арасында көче ягыннан аныкына тиңләнердәй шигырьләрнең булмавын белдерделәр.

XX гасыр башы татар әдәбияты көнчыгыштан килгән тамырларына тугърылыклы калып, шул ук вакытта Аурупа әдәбияты алып килгән яңалыкларга да ачык иде. Бу күренеш, әлбәттә, әдәбиятның шигърият, проза һәм драматургия кебек бөтен өлкәләре өчен уртак иде. Күренекле татар әдәбият галимнәре Г. Халит, Р. Ганиева, Х. Миңнегулов хезмәтләреннән дә билгеле булганча, Көнчыгыш Яңарыш чорының фәлсәфи, социаль, эстетик һәм этик идеяләре

XX йөз башы татар әдәбиятында моңарчы булмаган искиткеч зур көч белән барлыкка килә. Шуңа күрә, һичшиксез, Урта гасыр Көнчыгышның күп кенә шагыйрь һәм фикер ияләренең С. Рәмиевкә йогынтысы булган. Шагыйрь мәдрәсәдә укыган елларда ук, борынгы Көнчыгыш, бигрәк тә классик фарсы шигърияten яратып өйрәнгән. Фирдәүси, Сәгъди кебек классик шагыйрьләрнең әсәрләрен оригиналда укыган. С. Рәмиевнең рухи һәм иҗади эзләнүләренә гыйсьянчылык, Хәйям, Хафиз, Нәсими һәм башка шагыйрьләр иҗатындагы бунтарь һәм атеистик фикерләр бигрәк тә аваздаш булалар. С. Рәмиевнең гыйсьянчылыгын аңлау юлында урта гасырларда мөстәкыйль фикер йөртергә һәвәс кешеләрне һәрчак үзенә тартып торган, аларга ислам чикләрендә калып, чынбарлыкта аның чикләреннән чыгу мөмкинлеге дә тудырган суфичылык эчендә барлыкка килгән пантеизм куәтле чыганак булып тора. Урта гасыр пантеизмында Алла һәм җиһан күтәренке рухлы бербөтен итеп санала. Көнчыгышта азербайҗан шагыйре Имамеддин Нәсими иҗатында барлыкка килгән пантеистик суфичылык кешегә карата тирән хөрмәт хисләре уята, кешенең бөеклегенә мәдхия укый иде. С. Рәмиевнең «Алла» шигырендә «Мин – Ул, Ул – мин!» дип язуы Нәсиминең «Алла-кеше» фикерен хәтерләтә. Шагыйрь фикерләре һәм гамәлләре белән галилеккә ирешкән шәхес күңелендәге Алланы таный һәм Аны үзенең «мин»е белән бербөтен буларак кабул итә. Нәсими дә, Рәмиев тә һәркайсы һәр кешегә түгел, - азат, иң бөек тәртип кешесенә дан җырлыйлар. Кешегә карата мәхәббәт һәм ихтирам хисләре тәрбияләгән пантеистлар мәхәббәтне бөтен галәмне җанландыручы илаһи көч итеп аңлаталар. С. Рәмиев тә олы, саф мәхәббәткә дан җырлый. Җирдә яшәгән гадәти татар кызларын җиһандагы бөтен матурлыкны үзләренә җыйган илаһи затлар дип таный, алар каршында тез чүгә, аларга иң зур өметләрен баглап, милләтне яңартучы һәм саклап калучы миссиясен дә йөкли.

Шагыйрьнең 1906-1910 елларда язылган, татар милләтенең үзаңын уятуга багышланган һәм бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган «Таң вакыты» шигыре, Алла тарафыннан яратылган җанының тар кысаларга сыймавын, Жиргә һәм Күккә гыйсьян белдереп язылган һәм дөньяда үзенең «мин»леген тануда, үзенең азатлыгын моннан да куәтле сүз белән белдерүдә ише-тиңе булмаган «Мин» шигыре, хатын-кызның матурлыгына дан җырлап, аларны илаһи зат буларак кабул итеп язылган «Ул», «Син», «Җәмилә» исемле шигырьләре – алар барысы да дөнья шигърияtенең энҗеләре. С. Рәмиевнең шигырьләре шул ук вакытта рус әдәбияты контекстында да ирекле укыла. Ул рус шигъриятенә, бигрәк тә М. Лермонтов, К. Бальмонт шигырьләренә еш мөрәҗәгать итә, алардан илһам алып яза. С. Рәмиевнең шигырьләрендә Көнчыгыш әдәбиятыннан килгән гыйсьянчылык белән янәшә рус әдәбиятыннан, Лермонтов һәм Бальмонт иҗатыннан килгән демонизм да бар («Мин», «Көлсеннәр», «Дөньяга», «Мәҗит сүзе»). Шул ук вакытта Сәгыйть Рәмиевнең тирән фәлсәфи фикергә ия булган шигырьләре XIX йөз соңы - XX йөз башында Көнбатышта барлыкка килгән экзистенциализм фәлсәфәсенә дә аваздаш. Язмышның котылгысызлыгы, бу дөньяда бер генә нәрсәнең дә даими булмавы, һәрнәрсәнең туктаусыз үзгәреп торуы, кеше яшәешенең мәгънәсезлеге кебек мотивлар С. Рәмиевнең иҗатына да үтеп керә. Моң-зар, дөньядан читкә китү, ялгызлык, үлем кебек тирән фәлсәфи, экзистенциаль мотивлар бигрәк тә шагыйрьнең «Мин үләм» һәм «Күңелле булмадым» исемле шигырьләренә хас. С. Рәмиевнең иҗатын классик Көнчыгыш һәм XX йөз башы Көнбатыш фәлсәфи поэзиясе фонында карау безгә аның иҗади мөстәкыйльлеген, милли һәм бөтендөнья әдәбиятының гомуми үсешендә алып торган урынын танырга мөмкинлек бирә.

Г. Ибраһимов Сәгыйть Рәмиев иҗатының иң мөһим ягын күреп ала белгән: шагырь хыялында вак, гади тормыштан еракка, галәм киңлекләренә китеп тә, чынлыкта исә һаман шул үзе сөймәгән, түбән тормыш эчендә яшәргә мәҗбүр. Бу шагыйрь тарафыннан фаҗига буларак кабул ителә [Ибраһимов, 1978, б. 96]. Билгеле булганча, кеше төркеменнән читкә китеп, горур ялгызлыкта яшәү - шагыйрьләрнең үзләрен шәхес буларак саклап калу, үз иреген чиксез, абсолют итеп күрергә теләү нәтиҗәсе һәм ул бөтен романтик поэзия өчен уртак сыйфат. Соңрак бу хакта, «Сәгыйть Рәмиев тә, Дәрдемәнд тә «шәхес һәм илһам кеше төркеменнән читтә һәм өстен булырга тиеш» дигән фикердә», дип әдәбият белгечләре Х. Госман һәм Г. Халитләр дә язып чыктылар [Халит, 1979, б. 156]. С. Рәмиевне бөтендөнья әдәбияты классик шагыйрьләре - Байрон, Гете, Лермонтов, Ницше, Джебран, Бальмонтлар белән бер рәткә куярга мөмкинлек биргән сыйфатлар да өметсезлек һәм индивидуализм

иде. Шагыйрь иң матур, иң көчле шигырьләрен дә нәкъ шул өметсезлек эчендә караңгы реакция елларында яза. Г. Ибраһимов Сәгыйть Рәмиевне «салкын гакыл, коры мантыйк белән эш итмәүче, чын мәгънәсендә шагыйрь» дип билгеләвендә хаклы. С. Рәмиев бөтен гомерен чын хиссият колы буларак уздыра: еш кына төшенкелеккә бирелүләр, инде нишләргә дә белмичә аптырап калулар, хәтта үзен яклый алмас дәрәҗәдә гаҗиз булуы - болар барысы да аның шигырьләрендә ярсулы рәвештә кәефенең үзгәреп торуына, тормышында исә драматизм, киеренкелек барлыкка килүгә сәбәп була. Ләкин кара реакция елларында (1909-1911) тирән үпкә һәм рәнҗү белдереп язылган «Алданган», «Мин үләм», «Көлсеннәр», «Дөньяга», «Минем төн» шигырьләрендә дә Сәгыйть Рәмиев татарларның, бөтен кешелекнең якты киләчәгенә, караңгы төннәрнең артыннан туачак таңга өметләнеп яши. Аның лирик герое, дөньяда явызлык хөкем сөрүенә карамастан, камиллеккә һәм гармониягә омтыла.

С. Рәмиев, шигырьләр белән беррәттән, шул чорның иң әһәмиятле мәсьәләләрен үзәккә куйган хикәя, повесть һәм драма әсәрләре дә иҗат итә. 1907 елда языльп бетеп, 1908 елда аерым китап булып басылып чыккан һәм Сәйяр труппасы тарафыннан сәхнәгә куелган «Низамлы мәдрәсә» комедиясенә ул заманнарда иң алдынгы мәдрәсәләрдән берсе дип саналган, ләкин XX гасыр башында алдынгы карашлы татар яшьләренең таләпләренә җавап бирмәгән “Хөсәения” мәдрәсәсендә булып үткән вакыйгаларны нигез итеп ала. Шул ук 1907 елда язылган «Яшә, Зөбәйдә! – Яшим мин!» исемле пьесасында С. Рәмиев, XX йөз башында татар җәмгыяте тормышында алга чыккан мәгариф һәм тәрбия проблемалары белән беррәттән, хатын-кыз азатлыгы һәм алдынгы татар интеллигенциясенең әхлакый эзләнүләрен күрсәтә. Аның геройлары – белемле, хөр фикер йөртүче, халыкка хезмәт итү юлларын эзләүче, идеаллары һәм мәхәббәте өчен көрәшә белә торган шәхесләр.

С. Рәмиев Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һәм Г. Коләхмәтов белән бергә татар театрын булдыру эшендә дә актив катнаша. 1906 елның 2 декабрендә татар театры тарихында беренче рәсми спектакль Сәгыйть Рәмиевнең ялкынлы чыгышы һәм сәхнәгә чыккан беренче татар артистларына багышланган «Театр» шигыре белән ачыла. С. Рәмиев театр тарихы һәм тәнкыйте белән бәйле күп кенә мәкаләләр дә яза.

Шагыйрь яшәгән чор бик катлаулы, кискен бәрелешләр белән тулы, шагыйрьләр һәм шигъърият сәяси буяуларга буялып яшәргә мәҗбүр чор була. Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов һәм башка күп кенә шагыйрь һәм язучыларның фаҗигале язмышлары да бу хакта сөйли. Шуңа күрә Сәгыйть Рәмиевнең дә бер шәлкем шигырендә кеше эчке дөньясына үтеп керерлек күңел газабы, дөнья тәртибе белән килешмәү һәм моң булуы һич кенә дә гаҗәпләндерми.

**Әдәбият**


*Гайнетдинов, М.* Габдулла Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. Казан, 1997. Б. 72–80.

*Гыйрфанов К.*. Сәгыйть Рәмиев турында кайбер истәлекләр //Казан утлары. 1965. № 6. Б. 148–156.

*Ибраһимов Г.* Татар шагыйрьләре. // Г. Ибраһимов. Әсәрләр, сигез томда. 5 том. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1978. Б. 74–156.

*Рәмиев С.*. Таң вакыты. Шигырьләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре, публицистика. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980.272 б.

*Садретдинов Ш.* Архив материаллары ни сөйли? Кульязма. Ш. Садретдинов архивы. ТӘҺСИ мирасханәсе, 170 ф.

*Садретдинов Ш.* Сәгыйть Рәмиев (1880-1926).// Рәмиев, Сәгыйть. Таң вакыты. Шигырьләр, хикәяләр, сәхнә әсәрләре, публицистика. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1980. Б. 4–16.

*Садретдинов Ш.*. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1973. 162 б.

*Садретдинов Ш.* Сәгыйть Рәмиев һәм патша жандармериясе // Аргамак. 1994. № 6. Б. 92–101.

*Халит Г.* Яңа гасыр поэзиясе. Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1979. 168 б.

*Юлтый Д.* Сәгыйть Рәмиев үлде // Эшче. 1926. № 53 (Март).

*Әюпова-Рәмиева, Гыйззәт-Бану.* Истәлекләр.// «Уйласам уй, сызлый күңлем, сызлый җан...»: Сәгыйть Рәмиевнең тормыш юлы һәм иҗатына карата яңа мәгълүматлар. Төзүче-автор Чулпан Зарипова-Четин. Казан: Яңалиф., 2005. Б. 106–118.